**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.09.2016 № 509

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 27 сентябрендә теркәлде, № 3509

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше
һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча
комиссиясе хакында

"Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының "Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссияләр хакында" 2010 елның 1 июлендәге № 821 Указына, "Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы законына, Татарстан Республикасы Президентының "Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм

мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссияләр хакында” 2010 елның 25 августындагы № 569-ПУ Указына туры китереп **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссиясе хакында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Дәүләткә хезмәт итү һәм кадрлар бүлегенә: дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык белән расланган Нигезләмә белән таныштырырга.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2016 елның 5 сентябрендәге № 509 боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссиясе хакында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссиясе турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының “Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссияләр хакында” 2010 елның 1 июлендәге № 821 Указы, “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының “Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссияләр хакында” 2010 елның 25 августындагы № 569-ПУ Указы нигезендә эшләнде. Нигезләмә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштәге тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм эштәге тәртибенә таләпләр буенча комиссиясенең (алга таба – Комиссия) төзелү һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Үз эшчәнлегендә Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм бу Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы булып, булышу тора:

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр низагына юл куймау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, шулай ук аларның “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль закон белән, башка федераль законнар белән билгеләнгән йөкләмәләрне (алга таба – эштәге тәртипкә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләр) үтәвен тәэмин итүдә;

Министрлыкта коррупцияне булдырмый калу чараларын гамәлгә ашыруда.

1.4. Комиссия, Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфалары) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата, эштәге тәртипкә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләр үтәлешенә бәйләнгән мәсьәләләрне карап тикшерә (аларга билгеләү һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хәл ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән гайре).

1.5. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карап тикшерми, эш урынында дисциплина бозылу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары арасыннан министр тарафыннан билгеләнүче Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссиянең барлык

әгъзалары, карарлар кабул иткәндә, тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаган чакта, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына керәләр:

а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупциягә бәйле һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмый калу эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия сәркатибе), Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең дәүләт хезмәткәрләре, Министрлыкның юридик бүлеге хезмәткәрләре, Министрлыкның министр тарафыннан билгеләнүче башка бүлекчәләре хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләсе буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының эшчәнлекләре дәүләт хезмәте белән бәйләнгән вәкиле (вәкилләре).

2.3. Министр комиссия составына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкта эшләүче беренчел профсоюз оешмасы һәм ветераннарның Министрлыкта оештырылырга мөмкин булган иҗтимагый оешмасы вәкилләрен кертү турында карар кабул итәргә мөмкин.

2.4. Нигезләмәнең 2.2 пунктының “б” һәм “в” пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар, билгеләнгән тәртиптә, тиешле органнар һәм оешмалар белән килештереп, Комиссия составына министрның рәсми мөрәҗәгате нигезендә кертеләләр.

2.5. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләмәүче Комиссия әгъзаларының саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү ихтималы булмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Комиссия утырышларында киңәш бирүче тавыш хокукы белән

катнашалар:

а) аңа карата Комиссия эштәге тәртипкә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләр үтәлеше мәсьәләсен карап тикшерә торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнүче – Министрлыкта дәүләт хезмәтенең Комиссия тарафыннан аңа карата шушы мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре биләгән вазыйфасына охшаш вазыйфалар биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) дәүләтнең Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче бүтән хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия тарафыннан карап тикшерелүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алырлык белгечләр; дәүләтнең бүтән органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; мәнфәгатьле оешмаларның вәкилләре; аңа карата Комиссия эштәге тәртипкә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләр үтәлеше мәсьәләсен карап тикшерә торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле – Комиссия рәисенең һәрбер конкрет очракта аерым кабул ителә торган карары буенча, Комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көн кала Комиссия тарафыннан аңа карата шушы мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәренең яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенече нигезендә.

2.8. Әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән икесе катнашса, Комиссия утырышы законлы хокукка ия дип санала. Утырышларны Комиссиянең бары тик Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне карап тикшергәндә мәнфәгатьләр низагына китерү ихтималы булган туры яки кыек шәхси мәнфәгатьлелеге барлыкка килгәндә, бу хакта ул утырыш башланганчы әйтергә бурычлы. Андый очракта Комиссиянең әлеге әгъзасы әйтелгән мәсьәләне карап тикшерүдә катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыру өчен нигезләр булып торалар:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелүче мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын һәм дәүләт хезмәткәренең эштәге тәртипкә таләпләрне үтәвен Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына туры китереп уздырылган тикшерү йомгаклары буенча министрның түбәндәгеләрне дәлилләүче тикшерү материалларын тапшыруы:

дәүләт хезмәткәренең Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре турында, мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыруы хакындагы, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыруы хакындагы Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге № 702-ПУ Указы белән расланган нигезләмә белән күздә тотылган мәгълүматларны ялган һәм тулы булмаганча бирүе турында;

дәүләт хезмәткәренең эштәге тәртипкә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрне үтәмәве турында;

б) Министрлыкның норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә яисә дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны булдырмый калу буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи затына кергән:

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының Министрлык боерыгы белән расланган исемлегенә кертелгән, аларны биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырырга тиеш булган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән алып ике ел узганга кадәр коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләргә яисә гражданлык-хокукый килешү шартларында коммерцияле яки коммерциясез оешмада эш

башкарырга ризалык бирүе турында мөрәҗәгате, әгәр бу оешманы дәүләт тарафыннан идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт итү) бурычларына кергән булса;

дәүләт хезмәткәренең, объектив сәбәпләр аркасында, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру мөмкин булмау хакында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең, чит илнең компетентлы органнары тарафыннан, аның территориясендәге чит ил банкында счетлары (кертемнәре) булган, наличный акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләре саклана торган һәм (яки) финанс инструментлары булган әлеге чит ил дәүләтенең законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә, яки аның ихтыярыннан яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярыннан тормаучы башка хәлләргә бәйле рәвештә, 2013 елның 7 маендагы “Затларның аерым категорияләренә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның булуын, наличный акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләрен Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында саклауны, чит илнең финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) куллануны тыю турында” № 79-ФЗ Федераль законның (алга таба – “Затларның аерым категорияләренә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның булуын, наличный акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләрен Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында саклауны, чит илнең финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) куллануны тыю турында” Федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкин булмау турында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси мәнфәгатьләре барлыкка килү турында белдерүе;

в) министрның яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәренең эштәге тәртипкә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрне үтәвен тәэмин итүгә яисә Министрлыкта коррупцияне булдырмау буенча чаралар күрүгә кагылышлы тәкъдиме;

г) министрның дәүләт хезмәткәренең “Дәүләт вазыйфалары биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килү турында” № 23-ФЗ Федераль законның 3 статьясы 1 өлеше күздә тоткан дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар бирүе турында сөйләүче тикшерү материалларын тапшыруы;

д) коммерцияле яки коммерциясез оешманың Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт килешүе яки гражданлык-хокукый килешү төзелү турында 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясы 4 өлешенә һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясына туры китереп, Министрлыкка кергән хәбәрнамәсе, әгәр бу оешманы дәүләт тарафыннан идарә итүнең аерым функцияләре аның Министрлыкта вазыйфа биләгән вакытында үтәлгән вазыйфаи (хезмәт итү) бурычларына кергән булса, әлеге гражданинга элегрәк Комиссия бу оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләренә һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керергә рөхсәт итмәгән булу яки андый гражданинга аның коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләвенә яисә аның гражданлык-хокукый килешү шартларында коммерцияле яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруына ризалык бирү турындагы мәсьәлә Комиссия тарафыннан каралмаган булу шарты белән.

3.2. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында әйтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин тарафыннан, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи затына яисә Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә бирелә. Андый мөрәҗәгать кергәч, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, 3 эш көне эчендә, аны, карап тикшерү өчен, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи затына җибәрә. Мөрәҗәгатьтә күрсәтелә: гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туган көне, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел эчендә биләгән вазыйфаларын, коммерцияле яки коммерциясез оешманың атамасы, урнашкан урыны, аның эшчәнлеге характеры, гражданин дәүләт хезмәте

вазыйфасын биләгән вакытта ул үтәгән йөкләмәләр, коммерцияле яки коммерциясез оешмага карата дәүләт идарәсе буенча функцияләр, килешүнең төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), аның гамәлдә булуының фаразланучы срогы, килешү буенча эшләр башкарган (хезмәтләр күрсәткән) өчен түләү суммасы. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне карап тикшерә, шуның нәтиҗәләре буенча, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча нигезле йомгаклау нәтиҗәсе әзерләнә.

3.3. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтендәге эшеннән китәргә ниятләүче дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелергә мөмкин һәм бу Нигезләмәгә туры китереп, Комиссия тарафыннан карап тикшерелергә тиеш.

3.4. Бу Нигезләмәнең 3.4 пункты “д” пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясы таләпләрен үтәве турында нигезле йомгаклау нәтиҗәсен әзерли.

3.4.1. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул хәбәрнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгаклау нәтиҗәсен әзерли.

3.4.2. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне, яки бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “д” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгаклау нәтиҗәсен әзерләгәндә, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне яки хәбәрнамәне тапшырган дәүләт

хезмәткәре белән әңгәмә уздырырга һәм аңардан язмача аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен, Министрлык дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрергә мөмкин. Мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук йомгаклау нәтиҗәсе һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән алып җиде эш көне эчендә, Комиссия рәисенә тапшырыла. Рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү очрагында мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук йомгаклау нәтиҗәсе һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыкка түгел.

3.5. Комиссия рәисе, аңа Комиссия утырышын уздыру өчен нигезләрне үз эченә алучы мәгълүмат кергәндә:

а) 10 көнлек срокта Комиссия утырышы көнен билгели. Бу вакытта Комиссия утырышы көне әлеге мәгълүмат кергән көннән алып 20 көннән соң билгеләнә алмый, бу Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктлары күздә тоткан очраклардан гайре;

б) аңа карата Комиссия тарафыннан эштәге тәртипкә таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучыларны дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи затына кергән мәгълүмат белән, шулай ук әлеге мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыра;

в) Комиссия утырышына бу Нигезләмәнең 2.7 пункты “б” пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турында үтенечләрне карап тикшерә, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

3.6. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карап тикшерү буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр

турында мәгълүматлар бирү өчен билгеләнгән срок беткән көннән алып бер айдан соңга калмыйча уздырыла.

3.7. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “д” пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план буенча) утырышында карап тикшерелә.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата эштәге тәртипкә таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше хакындагы мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре яки Министрлыкта дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин катнашында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга җыенуы турында дәүләт гражданлык хезмәткәре яки гражданин бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасына туры китереп тапшырылучы мөрәҗәгатендә, гаризасында яки хәбәрнамәсендә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракта дәүләт хезмәткәре яки гражданин булмаганда уздырылырга мөмкин:

а) әгәр бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасы күздә тоткан мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрнамәдә дәүләт хезмәткәренең яки гражданинның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга җыенуы турында күрсәтелмәгән булса;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашырга җыенган, һәм аны уздыруның вакыты һәм урыны турында аңа тиешенчә хәбәр ителгән дәүләт хезмәткәре яки гражданин Комиссия утырышына килмәсәләр.

3.9. Дәүләт хезмәткәренең яки министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары Комиссия утырышында тыңлана, бу утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карап тикшерелә.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар Комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

3.11. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “а” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның үзләренең керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирүе хакындагы, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге № 702-ПУ Указы белән расланган нигезләмәгә туры китереп тапшырган мәгълүматлар дөреслеккә туры килә һәм тулы дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре бу пунктның беренче абзацында әйтелгән Нигезләмәгә туры китереп тапшырган мәгълүматлар дөреслеккә туры килми һәм (яки) тулы түгел дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.12. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “а” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре эштәге тәртипкә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрне үтәгән дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре эштәге тәртипкә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән дип билгеләргә. Бу очракта комиссия министрга эштәге тәртипкә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрне бозарга ярамавын дәүләт хезмәткәренә аңлатырга яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.13. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр бу оешманы дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт итү) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләргә яисә коммерцияле яки коммерциясез оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга гражданинга ризалык бирергә;

б) әгәр бу оешманы дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт итү) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерциясез оешмада

вазыйфа биләргә яисә коммерцияле яки коммерциясез оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга гражданинга рөхсәт бирүдән баш тартырга һәм баш тартуны дәлилләргә.

3.14. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасына өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирмәүнең сәбәбен объектив һәм әһәмиятле дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирмәүнең сәбәбен әһәмиятле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә әлеге мәгълүматларны бирү буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәре үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирмәүнең сәбәбен объектив түгел һәм әлеге мәгълүматларны бирүдән качарга тырышу ысулы дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

3.15. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының дүртенче абзацында курсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) “Затларның аерым категорияләрен Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачудан һәм булдырудан, наличный акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклаудан чит ил финансы инструментларына ия булудан һәм (яки) алардан файдаланудан тыю турында” федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы шартларны объектив һәм әһәмиятле дип танырга;

б) “Затларның аерым категорияләрен Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачудан һәм булдырудан, наличный акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклаудан чит ил финансы инструментларына ия булудан һәм (яки) алардан файдаланудан тыю турында” федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы шартларны объектив һәм әһәмиятле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.15.1. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре үзенең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагы юк дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре үзенең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, аның шәхси мәнфәгатьлелеге мәнфәгатьләр низагына китерә яки китерергә ихтимал дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) министрга мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча яки аның килеп чыгуына юл куймау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

3.16. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “в” пунктчасы күздә тоткан мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия тиешле карарны кабул итә.

3.17. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “г” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүне контрольдә тоту турында” Федераль законның 3 статьясы 1 өлешенә туры китереп, дәүләт хезмәткәре тапшырган мәгълүматлар дөреслеккә туры килә һәм тулы дип танырга;

б) “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүне контрольдә тоту турында” Федераль

законның 3 статьясы 1 өлешенә туры китереп, дәүләт хезмәткәре тапшырган мәгълүматлар дөреслеккә туры килми һәм тулы түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә һәм (яки) чыгымнарга контрольлек итү нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки), аларның вәкаләтләренә тәңгәл рәвештә, дәүләтнең башка органнарына җибәрергә киңәш итә.

3.18. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “д” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр бу оешманы дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт итү) бурычларына кергән булса, гражданинга коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләргә яисә коммерцияле яисә коммерциясез оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкарырга ризалык бирергә;

б) аның коммерцияле яки коммерциясез оешма хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләве һәм (яки) коммерцияле яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруы (хезмәтләр күрсәтүе) “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәр иткән оешмага мәгълүмат бирергә киңәш итә.

3.19. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а”, “б”, “г”, “д” пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү йомгаклары буенча, шуңа нигезләр булганда, Комиссия бу Нигезләмәнең 3.11 – 3.15.1, 3.17-3.18 пунктларында күздә тотылганнан үзгә карар кабул итәргә мөмкин. Андый карар кабул итүнең нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.20. Комиссиянең карарларын үтәү өчен, Министрлыкның норматив-хокукый актларының, министрның карарлары яки поручениеләренең проектлары әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә министрга карап тикшерүгә тапшырыла.

3.21. Комиссиянең бу Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия бүтән карар кабул итмәсә) Комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы

белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары аның утырышында катнашкан әгъзалары тарафыннан имзаланучы беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары, бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча кабул ителүче карардан гайре, министр өчен киңәш бирү рәвешендә була. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча кабул ителүче карар мәҗбүри була.

3.23. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтеләләр:

а) Комиссия утырышының көне, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында карап тикшерелүче һәр мәсьәләнең формулировкасы, аңа карата эштәге тәртипкә таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше хакындагы мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп;

в) дәүләт хезмәткәренә белдерелә торган дәгъвалар, алар нигезләнә торган материаллар;

г) белдерелүче дәгъваларның асылы буенча дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм алар чыгышының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышы уздыру өчен нигезләрне үз эченә алган мәгълүматның чыганагы, мәгълүматның Министрлыкка керү көне;

ж) бүтән мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.24. Комиссиянең Комиссия карары белән килешмәгән әгъзасы үз фикерен язмача бәян итәргә хокуклы, аның Комиссия утырышы беркетмәсенә кушып куелуы мәҗбүри һәм дәүләт хезмәткәре аның белән таныштырылырга тиеш.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш булган көннән

алып 7 көнлек срокта – министрга, тулысынча яки аннан өземтәләр рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча, мәнфәгатьле башка затларга җибәрелә.

3.26. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карап тикшерә һәм, үз вәкаләтләре чикләрендә, анда булган киңәшләрне дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары җаваплылык чараларын күрү турында, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның бүтән мәсьәләләре буенча карар кабул иткәндә исәпкә алырга хокуклы.

Комиссия киңәшләрен карап тикшерү турында һәм кабул ителгән карар турында министр аңа Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән бер айлык срокта Комиссиягә хәбәр итә.

3.27. Комиссия дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар тәртип бозу билгеләрен ачыклаган очракта, бу хакта мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән күздә тотылган җаваплылык чараларын күрү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, министрга тапшырыла.

3.28. Комиссия дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу фактын (гамәл кылмау фактын) ачыклаган очракта, Комиссия рәисе әлеге гамәлнең кылынуы (гамәл кылынмау) турында мәгълүматны һәм андый фактны раслаучы документларны хокук саклау органнарына өч көнлек срокта, ә зарурлык булганда – кичекмәстән тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аңардан өземтә аңа карата эштәге тәртипкә таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше хакындагы мәсьәлә карап тикшерелгән дәүләт хезмәткәренең “личное дело”сына кушып куела.

3.30. Комиссия карарыннан Комиссия сәркатибе имзасы һәм Министрлык мөһере белән расланган өземтә, кул куйдырып, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, аңа карата бу Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә карап тикшерелгән гражданинның кулына бирелә яки, Комиссиянең шул утырышы уздырылган көн артыннан килүче бер эш

көненнән соңга калмыйча, мөрәҗәгатендә ул күрсәткән адреска тапшырылуы турындагы хәбәрнамә белән заказлы хат итеп җибәрелә.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, утырыш уздыруның көне, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышу өчен бирелүче материаллар белән таныштыру дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны булдырмау буенча эшләү өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.